# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

«15» ноябрь, 2019 ел Яңа пос. № 10

2020 елга һәм 2021, 2022 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге бюджеты проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү турында

«2020 елга һәм 2021, 2022 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге бюджеты хакында» карар проекты буенча Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге халкының фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Әҗмәкәй авыл җирлеге уставы, «Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» нигезләмәгә таянып,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «2020 елга һәм 2021, 2022 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге бюджеты хакында» Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советы карар проекты (2019 елның 11 ноябрендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырылып, халыкка җиткерелгән) буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
2. Әлеге карарны 2019 елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча, җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Билгеләргә:

3.1. Халык тыңлауларын үткәрү вакытын: 2019 елның 28 ноябрендә 14.00 сәгатьтә;

3.2. халык тыңлауларын бер көндә үткәрергә;

3.3. үткәрү урыны: ТР, Тукай районы, Яңа пос., Үзәк ур., 1 й. (авыл мәдәният йорты, фойе);

3.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү, халык тыңлауларында катнашу өчен чыгыш ясау хокукы белән гаризалар бирү өчен адрес: ТР, Тукай районы, Яңа пос., Үзәк ур., 1 й., 5 каб. (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.20 сәгатькә кадәр).

4. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2020 елга һәм 2021, 2022 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге бюджеты хакында» карар проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Адиев